КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 август г.Казань № 1039

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм башкару турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә кош гриппының югары патогенлы вирусы чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Чайковский урамы, 44 нче йорт адресы буенча урнашкан «Лениногорск кошчылык фабрикасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территория чикләрендәге, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре, Тимәш авылы, Вәлиев поселогы, Савочкино авылы территорияләрендәге хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продукциясен алырга.

2. Бу карарга теркәлгән Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продукциясен алып юк итү буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү буенча махсус комиссиягә әлеге карарның 1 пунктында каралган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 август, 1039 нчы
карары белән расланды

Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү буенча
махсус комиссия составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Рашат Хәмит улы | «Лениногорск район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Галимуллин Айрат Наил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Түбән Кама территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Гатин Идрис Мөдәррис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Михайлова Зөлфия Габделхәмит кызы | Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

______________________________